КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 март г.Казань № 179

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карары белән расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивале турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер боерыклары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 14 июнь, 485 нче; 2018 ел, 24 август, 697 нче; 2019 ел, 19 апрель, 309 нчы; 2019 ел, 15 май, 394 нче һәм 2019 ел, 20 декабрь, 1177 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивале турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.4 нче пунктта татар текстында «хезмәт кенәгәсенең күчермәсен (барлык битләрен)» сүзләрен «тиешле рәвештә расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсен (барлык битләрен) һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясы белән билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны» сүзләренә алыштырырга;

5.5 нче пунктта «41 яшькә» сүзләрен «45 яшькә» сүзләренә алыштырырга;

5.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Фестивальдә катнашучыларның барысы да фестивальнең зона турлары башланганга кадәр Башкарма дирекциягә оешма җитәкчесе яки кадрлар хезмәте җитәкчесе тарафыннан расланган шәхесне таныклый торган документның, медицина иминият полисының күчермәләрен, файдаланыла торган фонограмма язмасын һәм фестивальдә катнашу өчен кирәкле реквизитны, шулай ук тиешле рәвештә расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсен (барлык битләрен) һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясы белән билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны тапшыра.»;

5.10 нчы пунктта «катнашучы командаларның номинацияләр буенча бәяләре яңадан исәпләнә» сүзләрен «җиңүче һәр номинация буенча барлык баллар җыелмасы буенча билгеләнә» сүзләренә алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 30 июнь, б-1311 нче; 2017 ел, 10 июнь, б-1250 нче; 2018 ел, 4 июнь, б-1345 нче; 2019 ел, 20 февраль, б-349 нчы һәм 2019 ел, 5 март, б-450 нче боерыклары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин